ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
КЫШЛАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ КШКЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Кшклово. Тел. 3-43-45

КАРАР

«09» ноябрь 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль
районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар, Яңа Өҗем
торак пунктларында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 22.11.2019 ел Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар, Яңа Өҗем торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар, Яңа Өҗем торак пунктларында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 22 ноябрь 2019 ел 18.00 сәг. тән 19.00 сәг. кадәр;
- үткәрү урыны – Кызыл Утар авылы, Ленин ур., 4 йорт, Кызыл Утар авыл клубы залы.

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 12 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Кышлау авылы, Татарстан урамы, 7 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Кызыл-Утар, Яңа Өҗем торак пунктларында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Кызыл Утар, Яңа Өҗем торак пунктлары халкына гражданнар җыены турында мәгълүматны мәгълүмати стендлар аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәьәләне расларга:

Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Кызыл Утар, Яңа Өҗем торак пунктлары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара

салым кертү һәм акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1). Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- Кызыл Утар һәм Яңа Өҗем авыллары территориясендә агач һәм куакларны чистарту һәм кисү;
2). Җирләү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:
- Кызыл Утар, Яңа Өҗем авыллары зиратларына элмә такталар һәм хуҗалык материаллары сатып алу.

“РИЗА” “КАРШЫ”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында “Интернет” мәълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Кызыл Утар авылы, Ленин ур., 4 йорт, авыл клубы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Шакирова